**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге башкарма комитеты**
**КАРАРЫ**

2015 елның 1 апреле 14№

2015 елга Әлки муниципаль районы Иске
Салман авыл җирлегендә коррупциягә
каршы тору буенча чаралар планын раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 11 апрелендәге «2014-2015 елларга коррупциягә каршы көрәшнең милли планы турында» 226 номерлы Әмерен үтәү йөзеннән Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2015 елга Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар планын (1-нче кушымта) расларга.
2. Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибына План үтәлешенә квартал саен мониторинг ясарга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Иске Салман авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: И.Г.Җәләлетдинов

Әлки муниципаль районының Иске
Салман авыл җирлеге Башкарма комитетының
2015 елның 1 апрелендәге 14 номерлы
карарына кушымта

**2015 елга Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлегендә коррупциягә каршы тору буенча чаралар планы**

| № т/б | Чаралар | Үтәү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| | **1. Коррупциягә каршы көрәшкә юнәлдерелгән хокук һәм оештыру чараларын тәэмин итү,** | | |
| 1.1. | Федераль һәм республика законнарын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында гамәлдәге коррупциягә каршы нормаларны куллану практикасын гомумиләштерү нигезендә коррупциягә каршы көрәш турында муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет сәркатибы |
| 1.2 | Муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне вакытында бирүен тикшерү | 2015елның 30 апреленә кадәр. | Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.3 | Муниципаль хезмәт турында, коррупциягә каршы тору хакында законнарның таләпләрен үтәп, хезмәткәрләрнең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү:<br>муниципаль хезмәткәрләрнең;<br>муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның | 2015 елның 2 кварталы | Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.4 | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт | Ел дәвамында | Әлки муниципаль районы Иске |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турындагы законнарда каралган чикләү һәм тыюларның үтәлешенә тикшерү үткәрү | | Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 1.5 | Законнар нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне законнарда билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыру. | 2015 елның 2 кварталы | Әлки муниципаль районының Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **2. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә иҗтимагый контроль механизмнарын булдыру, кире элемтә системасын билгеләү җирле үзидарә органнары эшчәнлеге өчен, кире элемтә системасын билгеләү** | | | |
| 2.1 | Иске Салман авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлегендә коррупция фактлары турында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау сроклары һәм нәтиҗәләренә анализ ясау | квартал саен | Башкарма комитет сәркатибы |
| 2.2 | Законнарда билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында район сайтында законнар нигезендә белешмәләр урнаштыру | 2015 елның 2 кварталы | Әлки муниципаль районы Иске Салман авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2.3 | Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә Иске Салман авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге һәм ачыклыгын тәэмин итү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет сәркатибы |
| **3.Норматив хокукый актлар һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза актлар һәм аларның проектлары** | | | |
| 3.1 | Норматив хокукый актлар һәм аларның проектларына | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен Әлки муниципаль районы Советына бирү | | | Башкарма комитет сәркатибы |
| **4. Муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштырганда коррупциягә каршы тору** | | | | |
| 4.1 | 2013 елның 05 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү | | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |